# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ
**(IV чакырылыш)**

егерменче утырыш

**КАРАРЫ**

11 июль 2022 ел **№ 134** Теләче ав.

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2021 елның 7 октябрендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча совет каршындагы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары структурасын камилләштерү мәсьәләләре буенча эш төркеме утырышының 2022 елның 3 июнендәге 11 номерлы беркетмәсен карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Теләче муниципаль район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2021 елның 7 октябрендәге 81 номерлы «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау һәм аның хезмәткәрләренең иң чик санын билгеләү турында» карары (27.12.2021 № 105 карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының структурасына үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә, түбәндәге эчтәлектә бәян итеп.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә һәм 2022 елның 1 сентябреннән барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Теләче муниципаль
Районы Башлыгы Н.Н. Хаҗипов

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль район Советының 2022 елның 11 июлендәге 134 номерлы карарына кушымта (27.12.2021 №105 карарлар редакциясендә)

## Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты структурасы

